ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«01» апрель 2019 г.

**КАРАР**
№ 41

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегендә, хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган, җирләү буенча хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы карары, «Татарстан Республикасында Күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Россия Федерациясе хөкүмәтенең «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән башлап җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Чепья авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Галиев

Чепья авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 01 апрель аенда кабул ителгән 41 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегендә хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең 2019 елның 1 февраленнән бәясе

| Хезмәт исеме | Бәясе, сумнарда |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәк булган табут һәм башка әйберләрне бирү, китерү | 2616,75 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 737,66 |
| 4. Мәетне күмү (каберне казу һәм күмү) | 2592,06 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Чепья авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның апрель аенда кабул ителгән 41 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегендә хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең 2019 елның 1 февраленнән бәясе

| Хезмәт исеме | Бәясе, сумнарда |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 225,36 |
| 3. Җирләү өчен кирәк булган табут һәм башка әйберләрне бирү, китерү | 2391,41 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 738,05 |
| 5. Мәетне күмү (каберне казу һәм күмү) | 2591,65 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |